**“Бакчабызның үткәне, бүгенгесе, киләчәге”**

1961 нче елның 29 нчы августында , Лениногорск шәһәре башкарма комитеты ТАССР депутатлары кабул иткән 35/20 нче номерлы карары нигезендә, бакчабыз 8 нче номерлы ясле балалар бакчасы буларак оештырыла һәм шәһәребезнең нәкъ уртасында урнаша.

1961 нче елда Миронова Валентина Сергей кызы бакча мөдире итеп билгеләнә.

1987 нче елда Мальцева Раиса Алексей кызы бакча мөдире итеп билгеләнә.

1991 елның 2 нче августында 8 нче номерлы балалар ясле бакчасына, үзгәртеп кору белән бәйле рәвештә, Лениногорск шәһәре ГорОО №127 нче боерыгы нигезендә, 33 нче тәртип номеры белән “Карлыгач” исеме бирелә.

1992 нче елда Хакимова Роза Әнвар кызы бакча мөдире итеп билгеләнә.

1995 нче елда балалар бакчасы коллективы шәһәр күләмендә уздырылган “Милли балалар бакчасында туган телне өйрәнү” бәйгесендә 3 нче урынга ия була, Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

1996 нчы елда балалар бакчасы коллективы шәһәр күләмендә уздырылган “Ел балалар бакчасы” бәйгесендә җиңү яулый.

1997 нче елда Гайнутдинова Аймара Марсель кызы бакча мөдире итеп билгеләнә.

1999 нчы елда Низамова Гөлфия Яхия кызы бакча мөдире итеп билгеләнә һәм бүгенге көнгә кадәр бакча белән җитәкчелек итә.

Татарстан Республикасы "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2006 нчы елның 3 нче апрелендәге № 53 нче карары нигезендә балалар бакчасының исеме үзгәртелә. Яңа исеме: Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының "Лениногорск шәһәренең 33 нче балалар бакчасы "муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе”

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2011 нче елның №50 нче карары нигезендә, тәртип номеры үзгәртелә: «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «4 нче балалар бакчасы» муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе.

2007 нче елдан «Лениногорск тампонаж эшләре идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте  бакчабызны үз канаты астына ала һәм даими ярдәм итә. Алар ярдәме белән бакчабызда балалар уен мәйданчыклары, сукмаклар яңартыла, техник база тулылана.

2018 нче елда Республика программасы буенча балалар бакчасында капиталь ремонт уздырыла. Бакчабыз яңара, яшәрә, матурлана.